РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

« 12 » декабрь 2024 ел №284

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы авыл җирлекләренең генераль планнарын әзерләү кирәклеге булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә, Ивашкино, Күтәмә, Мордва Афонькәсе, Түбән Кәминкә, Түбән Кармалка, Яңа Элмәле, Яңа Кади, Иске Кади, Иске Котыш, Иске Үтәмеш, Туймәт, Шешминка авыл җирлекләре территориясендә җирлекләр территорияләреннән гамәлдәге файдалануны үзгәртү күздә тотылмау, комплекслы социаль - икътисадый үсешнең расланган программалары булмау һәм Татарстан Республикасының һәм Чирмешән муниципаль районының территориаль планлаштыру схемаларында федераль, төбәк һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмау сәбәпле Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2025 елның 31 мартына кадәр Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә, Ивашкино, Күтәмә, Мордва Афонькәсе, Түбән Кәминкә, Түбән Кармалка, Яңа Элмәле, Яңа Кади, Иске Кади, Иске Котыш, Иске Үтәмеш, Туймәт, Шешминка авыл җирлекләре генераль планнарын әзерләү кирәк булмавын танырга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов